Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

№9 «07»май 2020 ел

«2020-2023 елларга Әҗмәр авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Әҗмәр авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен уңайлы икътисадый мохит булдыру максатларында, Әҗмәр авыл җирлеге администрациясе,

Карар бирә:

1. «2020-2023 елларга Әҗмәр авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын (кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://www.spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Әҗмәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе Р.М.Вәлитов